ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «08» ноября 2021 г.** **№ 1189**

**2022 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты нигезендщ Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1.Кушымтада бирелгән түбәндәгеләрне 2022 елга расларга:

Арча муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләре каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне матди карап тотуга норматив чыгымнар;

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» МКУнә әлеге карарның 1 пункты белән расланган гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә гомуми белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Э.Ш.Вафинага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р. Мөхәрәмов

Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 08.11.2021 ел, № 1189 карары белән расланды

**Арча муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль урнашуы | Бер тәрбияләнүчегә елына норматив чыгымнар, сумнарда |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | шәһәр җирлеге | 97 391 |
| | авыл җирлеге | 98 753 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җирлеге | 143 889 |
| | авыл җирлеге | 148 363 |